ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.06.2024 Олы Кайбыч ав. № 194

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы милкендәге арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне сатып алуга кече һәм урта эшкуарлык субъектларының өстенлекле хокукларын гамәлгә ашырганда һәм мондый мөлкәтне арендалау өчен түләүне кичектерү срогын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт милкендә яисә муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы милкендәге арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне сатып алуга кече һәм урта эшкуарлык субъектларының өстенлекле хокукларын гамәлгә ашырганда һәм мондый мөлкәтне арендалау өчен түләү күчемсез милек өчен 5 ел һәм күчемле милек өчен 3 ел тәшкил итә.

2. Арендалана торган мөлкәткә түләү тәртибен (бер үк вакытта яисә өлешләп) сайлау хокукы, шулай ук әлеге карарның 1 п.1 пункты нигезендә билгеләнгән чикләрдә кичектереп түләү срогы арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече яисә урта эшкуарлык субъектына карый.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары Э.Х.Заһидуллинага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров